# OUTSTANDING DOCTOR AND SCHOLAR ABUBEKIR TEREGULOV (ON THE 130$^{TH}$ ANNIVERSARY OF HIS BIRTH)

**Rashid Aglievich Shakirzayanov,**
Kazan State University of Architecture and Engineering,
1 Zelenaya Str., Kazan, 420043, Russia,
rashitagl@mail.ru.



**TEREGULOV ABUBEKIR GIREEVICH** (1885-1966) – general physician, Doctor of Medical Sciences (1927), Professor (1929), Honoured Scientist of the Tatar ASSR and the Russian SFSR (1940). He was a zemsky doctor after graduating from the Medicine Faculty of Kazan University in 1911, and from 1913 he was working as an attending physician in Kazan hospitals. In 1918, he was the Head of the Therapeutic Hospital of the Medicine Faculty in Tomsk University and from 1919, the Head of the Pathology and Internal Diseases Diagnostics Department in Irkutsk University. His doctoral thesis is devoted to “The Role of the Rachidian Bulb in Breath Regulation”. From 1921 he was the Head of Propaedeutics of the Internal Diseases Department (1929-1943) and the Nosocomial Therapy Department (1944-1964) of the Medicine Faculty in the Kazan State University and the Department of General Medicine in the Kazan State Medical Institute. At the same time (for 9 years) he was a vice-rector for academic work in the Kazan State Medical Institute. He went to great

**ТЕРЕГУЛОВ ӘБУБӘКЕР ГӘРӘЙ улы** (1885-1966) – табиб-терапевт, медицина фәннәре докторы (1927), профессор (1929), ТАССРның һәм РСФСРның (1940) атказанган фән эшлеклесе. 1911 елда Казан университетының медицина факультетын тәмамлагач, Уфа губернасында земство табибы, 1913 елдан Казан клиникаларында ординатор. 1918дә Томск, 1919дан Иркутск университетларында: медицина факультетының терапевтика клиникасын җитәкли, эчке авырулар патологиясе һәм диагностикасы кафедрасы мөдире. 1927 елда «Озынча минең сулыш көйләүдәге роле» дигән темага докторлык диссертациясен яклый. 1921 елдан Казанда КДУның медицина факультетында һәм КДМИның дәвалау факультетларында, эчке авырулар пропедевтикасы (1929-1943), госпиталь терапиясе (1944-1964) кафедралары мөдире. Бер үк вакытта (9 ел) КДМИның укыту эшләре буенча проректоры. «Казан медицина

**ТЕРЕГУЛОВ АБУБЕКИР ГИРЕЕВИЧ** (1885-1966) – врач-терапевт, доктор медицинских наук (1927), профессор (1929), заслуженный деятель науки ТАССР и РСФСР (1940). После окончания в 1911 году медицинского факультета Казанского университета работает земским врачом в Уфимской губернии, с 1913 – ординатор в Казанских клиниках. В 1918 году в Томском, с 1919 года в Иркутском университетах: руководитель терапевтической клиники медицинского факультета, заведующий кафедрой частной патологии и диагностики внутренних болезней. Тема докторской диссертации: «О роли продолговатого мозга в регуляции дыхания» (1927). С 1921 в Казани на медицинском факультете КГУ и лечебном факультете КГМИ, заведующий кафедрами пропедевтики внутренних болезней (1929-1943), госпитальной терапии (1944-1964). Одновременно, в течение 9 лет, проректор КГМИ по учебной работе. Приложил много усилий для возобновления издания «Казанского медицинского журнала», в 1957-1959 гг.

lengths to revive the publication of the *Kazan Medical Journal*, of which he was editor from 1957-1959. He was awarded the Order of Lenin, two Orders of the Red Banner of Labour and medals.

His main works are devoted to the issue of the functional pathology of digestive system organs and peptic ulcers and to the study of liver system bile-ducts.

журналы»н яңадан торгызуга зур көч куя, 1957-1959 елларда аның мөхәррире. Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр белән бүләкләнгән.

Төп гыйльми хезмәтләре аш кайнату әгъзаларының функциональ патологиясе, язва авыруы проблемаларына, бавырның үт бүлеп чыгару системасын тикшерүгә багышланган.

его редактор. Награжден орденом Ленина, двумя орденами Трудового Красного Знамени, медалями.

Основные научные труды посвящены проблеме функциональной патологии органов пищеварения, язвенной болезни, изучению желчевыводящей системы печени.

This person traces his descent back to the Teregulov dynasty known as Tatar mirzas. He was born on February 1, 1885 in Ufa, into the family of Garay Badamshaevich Teregulov, the Head of the Department of the Muslim Spiritual Directorate.

Abubekir began to study at a gymnasium in Ufa in 1898. After his father's death in 1902, the teenager had to earn money going from door to door, teaching children and, in spite of all his troubles, he continued his studies.

After graduating from the gymnasium in 1906, Abubekir entered the Faculty of Sciences of Kazan University, but within a year he moved to the Faculty of Medicine. He said later that he had a strong desire to devote his life to medicine after reading V.V.Veresaev's *Doctor's Notes*.

At the time when Abubekir Teregulov began to gain knowledge and experience in medicine, Kazan University was already famous for its talented teachers and professors.

The Head of the Department of Physiology was N.A.Mislavsky, the world famous scholar who later became A.G.Teregulov's scientific supervisor. Professor V.N.Tonkov, the author of a widely used textbook on anatomy, was the Head of the Department of Anatomy, Professor V.O.Gruzdev was the Head of the Department of Obstetrics and Gynaecology, and the outstanding neuropathist L.O.Darkshevich was the Head of the Department of Neuroscience.

At the beginning of his studies, it became clear that A.G.Teregulov had the dedication and ability for studying internal diseases. In 1909, when he was a third-year student, he gained his first sanitary and treatment skills during his summer holidays, while he was assisting in the protection from cholera, which suddenly spread in Aktash village of Minzelinsk province. The future doctor clearly understood that he needed great diligence and knowledge in order to save people's lives, and a great sense of responsibility for his patients.

In 1911, A.G.Teregulov graduated from the Medicine Faculty of Kazan University with a high-prestige degree as "a very good doctor". He was one of the few college-bred Tatars at the beginning of the 20th century. The outstanding Kazan professor A.N.Kazembek believed in him and offered Abubekir a place in the teaching hospital of the Medicine Faculty to get his residency training. Before beginning this kind of postgraduate study in medicine, A.G.Teregulov wanted to strengthen his practical knowledge by working among the people, thus he became a zemsky doctor in the Chishma station of Ufa province. He had to be a general practitioner, a pediatrist, a gynaecologist, a dentist and sometimes even a surgeon. And the experience, which he obtained during those years, became the basis of the future professor's professional success.

He returned to Kazan University after two years and completed his postgraduate studies. From 1917, he began working as an assistant lecturer in the Therapeutic Hospital of the Faculty.

During the Civil War Abubekir Teregulov went to Siberia with a group of scholars: he worked in Tomsk University in 1918, and in Irkutsk University in 1919-1921. He and his colleagues did much to organize the Medicine Faculty in Irkutsk University. The young doctor founded the Therapeutic Hospital and became its head. Teregulov was the Head of Pathology and Diagnosticity of the Internal Diseases Department. But in spite of his great success, the city of his youth – Kazan, and its scientific world, called to his soul. A.G.Teregulov was elected an assistant lecturer of the Therapeutic Hospital in Kazan State University in 1921, and he began to do extensive research and social work.

Abubekir Teregulov started his scientific work in the laboratory of outstanding physiologist Professor N.A.Mislavsky. He became extremely interested in a breath regulation problem, which was considered to be a very serious problem at that time. As a result of his careful research, the scientist proved that the breath rhythm was connected

with an independent breath centre. A.G.Teregulov defended his doctorate thesis on the topic "The Role of the Rachidian Bulb in Breath Regulation" in 1927, and was then elected a privat-docent of Kazan State University.

By 1929 the scholar had had considerable success in work and science. He was appointed the Head of the Propaedeutics Department of the University, which dealt with internal diseases, and was awarded the academic rank of 'Professor'. When an independent Institute was formed on the basis of the Medicine Faculty of Kazan University, he was a Vice-rector for academic work in the Kazan Medical Institute from 1931, paying special attention to the processes of education and treatment, and at the same time doing serious scientific work. During the 14 years that he was the Head of the Propaedeutics Department, the scholar published 15 significant articles, three of them devoted to X-ray diagnostics. During those years Abubekir Teregulov took part in plenary sessions of the Tatar ASSR Party and was elected a delegate of the 7th Special All-Russian Congress of the USSR in 1936. Due to his prominent work in medicine, he became the Honoured Scientist of the Tatar ASSR and the Russian SFSR in 1940 and was awarded the Order of the Red Banner of Labour.

During the Great Patriotic War A.G.Teregulov used all his energy and talent to retain the educational and treatment processes: he worked in the hospital, treated injuries of the lungs, heart and the hemal system and war time chancres, and wrote scientific works about the above-mentioned cases [1; 2]. The scholar was elected the Head of the Hospital Therapy Department of the Kazan State Medical Institute in 1944. He made major changes to the function of the Department, opened the branch designed for 150 places in the 7th hospital, and supplied its laboratory with brand new diagnostic equipment. Talented doctors who had been taught by Teregulov, were working in the Department. The treatment was organized to a very high standard and new methods of treatment were discovered at the hospital. The Professor used to see patients three times a week and enquired about their health. As the head of department and a unique clinician, Teregulov shared his talent and experience with colleagues, hospital physicians, postgraduates and students.

During the post-war period A.G.Teregulov deviated from the subjects of breath physiology and pathology to study the organs of the digestive system. He covered the new problem in his reports at high-level conferences and congresses. He gave an important report at the therapists' 13th congress in 1947, where he raised a point of diagnostics and a treatment for chancre. Five Doctoral and eleven Candidate dissertations were defended under the supervision of A.G.Teregulov, and more than 200 tractates, which had a positive effect, were published on the new topic of hospital work.

The scholar led an active social life. He was the deputy of the 2nd, 3rd, 4th and 5th callings of the Supreme Soviet of the Tatar ASSR, the Head of the Council of Kazan Medical scientific organizations, and the Head of the Tatar ASSR scientific association of therapists. Teregulov was elected a member of the management team of the All-Russian Association of Therapists. He was awarded Medals of Honour for his serious activities and achievements. The famous scientist was awarded the Order of the Red Banner of Labour for the second time in 1950 and the Order of Lenin in 1952.

In order to use the modern achievements of science and technology more widely, A.G.Teregulov's Department came forward with an initiative to organize a special design-engineering office. Kazan branched out with the new plant "Medfizpribor" in 1955. This plant produced new devices, instruments and appliances for examining and treating the patient's breath and other functioning organs. The Department became a clinically experimental facility of the plant.

A.G.Teregulov went to great lengths to revive the publication of the *Kazan Medical Journal* in 1957. This had been published for a long time but had ceased during the war period. He was the editor of this journal which became very important to the people of the Volga region.

A.Teregulov did his best to promote Izhevsk water which is still widely used for gastrotherapy. The scholar's works were devoted to such professors who had laid down the groundwork and developed the work of the Kazan Therapeutic School, and among them N.A.Vinogradov, A.N.Kazembek, S.S.Zimnitskiy, N.K.Goryaev and M.N.Cheboksarov are worth mentioning.

Even though A.G.Teregulov retired in 1963, he never moved away from the work of the Department, and remained its supervisor. His previous scientific works had thrown light upon the stomach, and its connection with the brain, kidney function and problems of the heart, but his last researches were devoted to the study and control of atherosclerosis – a widespread disease and the bane of mankind.

The scholar died in 1966 at the age of 81.

Abubekir Gireevich Teregulov was famous as the first Tatar professor in Medicine. He came to be seen as a teacher who achieved great results in this area, an incredibly hard-working person, a talented doctor-therapist, and a teacher of several generations of doctors. The 1st hospital in Kazan and one street in the Gorky-3 housing complex were named in honour of Professor A.G.Teregulov. The Academy of Sciences of the Tatarstan Republic formed an award named after A.G.Teregulov for significant works in Medicine. He became an archetype of Abuzar in G.Absalyamov's novel "The White Flowers", and his fine image found a reflection in literature.


**References**

1. *Teregulov A.G.* Bolezni organov krovoobrashcheniya – ostrye miokardity; ostryy revmatizm / Spravochnik nachinayushchego sovetskogo vracha. Kazan': Tatizdat, 1933. S. 65-87. (in Russian)
2. *Teregulov A.G.* Kliniko-laboratornoe issledovanie i kuratsiya bol'nogo s zabolevaniem vnutrennikh organov. Kazan': Tatknigoizdat, 1959. 120 s. (in Russian)
3. *Abdrakhmanova A.Sh., Mayanskoya K.A.* Professor Abubekir Gireevich Teregulov // Kazanskiy meditsinskiy zhurnal. 1985. T. 86, №2. S. 155-156. (in Russian)
4. *Shämsetdinov N.Sh.* Äbybäker Teregulov häm anyŋ ižaty // "Fän häm tel" zhurnaly, 2000, №1. 33-35 b. (in Tatar)


# КҮРЕНЕКЛЕ ТАБИБ ҺӘМ ГАЛИМ ӘБҮБӘКЕР ТЕРЕГУЛОВ (ТУУЫНА 130 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН)


**Рәшит Әгълә улы Шакирҗанов,**
Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты,
Россия, 420043, Казан ш., Зелёная ур., 1 нче йорт,
rashitagl@mail.ru.


Чыгышы белән борынгы татар морзалары Тередуловлар нәселеннән булган бу олы шәхес 1885 елның 1 февралендә Уфа шәһәрендә мөселман Диния нәзарәтенең бүлек җитәкчесе Гәрәй Бадамша улы Терегулов гаиләсендә дөньяга килә.

Әбүбәкер 1898 елда Уфа гимназиясендә укый башлый. 1902 елда әтисе вафат булгач, яшүсмер малай, өйләргә йөреп, аерым кешеләрнең балаларына дәресләр бирү юлы белән акча таба һәм, авырлыкларга карамыйча, укуын дәвам итә.

Гимназияне 1906 елда тәмамлап, Әбүбәкер Казан университетының табигать фәннәре факультетына укырга керә, әмма бер елдан медицина факультетына күчә. Үзе соңрак сөйләгәнчә, В.В.Вересаевның «Врач язмалары» исемле китабын укыгач, аңарда тормышын медицинага багышлау теләге туа.

Әбүбәкер Терегулов медицина өлкәсендә белем һәм тәҗрибә туплый башлаган елларда Казан университеты талантлы педагоглары, профессорлары белән дан тота. Дөньяга мәгълүм галим, соңрак Ә.Г.Терегуловның фәнни остазы булган профессор Н.А.Миславский физиология кафедрасы мөдире була. Анатомиядән киң таралган дәреслек авторы профессор В.Н.Тонков анатомия кафедрасын, профессор В.О.Груздев акушерлык һәм гинекология кафедрасын, мәшһүр невропатолог Л.О.Даркшевич неврология кафедрасын җитәкли.

Укый башлаганда ук, Ә.Г.Терегуловта кешенең эчке әгъзаларындагы авыруларны тикшерүгә омтылыш һәм сәләт булуы ачыклана. 1909 елда, өченче курс студенты чагында, ул җәйге каникул вакытында Минзәлә өязенең Акташ авылында кинәт таралып киткән ваба (холера) чиренә каршы көрәштә катнашып, беренче санитария-дәвалау күнекмәләре ала. Булачак табиб кеше гомерен саклап калу өчен күп тырышлык, белем кирәклеген, авыру алдында зур җаваплылык тойгысын чын-чынлап аңлый.

1911 елда Ә.Г.Терегулов Казан университетының медицина факультетын «бик яхшы табиб» дигән дәрәҗәле исем белән тәмамлый. Ул XX гасыр башында югары белем алган азсанлы татарларның берсе булып тора. Атаклы Казан профессоры А.Н.Казем-Бек аңа зур өметләр баглый, медицина факультетында үзе җитәкләгән клиникада калып, ординаторлык хезмәтен башкарырга тәкъдим ясый. Әмма, медицина аспирантурасының бер төре булган бу җитди хезмәткә керешкәнче, Ә.Г.Терегулов белемнәрен гамәлдә, халык арасында эшләп ныгытырга тели һәм Уфа губернасының Чишмә станциясенә земство

табибы булып китә. Анда аңа терапевт та, педиатр да, гинеколог та, стоматолог та, аерым очракларда хирург та булырга туры килә. Нәкъ менә шушы елларда туплаган тәҗрибәсе булачак профессорның һөнәри уңышларына нигез сала.

Ике елдан соң, ул Казан университетына кайта, ординатура тәмамлый, 1917 елдан факультетның терапия клиникасы ассистенты вазифасын башкара башлый.

Гражданнар сугышы чорында Әбүбәкер Терегулов бер төркем галимнәр белән Себергә китә: 1918 елда Томск, 1919-1921 елларда Иркутск университетларында эшли. Коллегалары белән бергә, Иркутск югары уку йортының медицина факультетын оештыруга күп көч куя. Яшь табиб терапевтика клиникасына нигез сала, аны җитәкли, эчке авырулар патологиясе һәм диагностикасы кафедрасы мөдире була. Әмма, зур уңышлары булуга карамастан, аның күңелен яшьлек каласы Казан, андагы фән дөньясы үзенә тарта. 1921 елда Ә.Г.Терегулов Казан университетының терапевтика клиникасына ассистент булып сайлана, фән һәм иҗтимагый эшчәнлек белән актив шөгыльләнә башлый.

Әбүбәкер Терегулов гыйльми эшчәнлеген мәшһүр физиолог профессор Н.А.Миславский лабораториясендә башлап җибәрә, шул чорда катлаулы мәсьәлә саналган сулышны көйләү проблемасы белән кызыксына башлый. Тирәнтен тикшеренүләр үткәрү нәтиҗәсендә, моңарчы яшәгән карашны кире кагып, сулыш ритмикасының автоном сулыш үзәгенә бәйле булуын исбатлый. 1927 елда Ә.Г.Терегулов «Озынча минең сулыш көйләүдәге роле (О роли продолговатого мозга в регуляции дыхания)» дигән темага докторлык диссертациясен уңышлы яклый, шуннан соң КДУның приват-доценты итеп сайлана.

Хезмәттә һәм фәндә уңышларга ирешкән галим 1929 елда университетның эчке әгъза чирләрен тикшерү белән шөгыльләнә торган пропедевтика кафедрасының мөдире итеп билгеләнә һәм аңа профессор гыйльми дәрәҗәсе бирелә. КДУның медицина факультеты нигезендә мөстәкыйль институт барлыкка килгәч, ул 1931 елдан Казан медицина институтының уку-укыту эшләре буенча проректоры була, укыту һәм дәвалау процессларына зур игътибар бирә, бер үк вакытта зур фәнни эш тә алып бара. Пропедевтика кафедрасын җитәкләгән ундүрт ел дәвамында галим унбиш җитди мәкалә бастырып чыгара, шуларның өчесе рентгенодиагностикага багышланган. Бу елларда Әбүбәкер Терегулов ТАССРның партия пленумнарында катнаша, 1936 елда Советларның VII Махсус Бөтенсоюз съездына делегат булып сайлана. Медицина өлкәсендәге хезмәтләре өчен 1940 елда аңа ТАССРның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе дигән исемнәр бирелә, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

Бөек Ватан сугышы елларында Ә.Г.Терегулов, уку-укыту, дәвалау барышын сүлпәнләндермәү өчен, бар көчен һәм талантын бирә: эвакогоспитальдә эшли, үпкә, йөрәк һәм кан тамырлары системасы яраларын, сугыш чоры яраларын дәвалый, шулар буенча гыйльми хезмәтләр яза [1; 2]. 1944 елда галим КДМИның госпиталь терапиясе кафедрасы мөдире итеп сайлана. Ул бу кафедраның эшчәнлеген тамырдан үзгәртеп, җиденче хастаханәдә аның 150 урынга исәпләнгән филиалын оештыра, лабораториясен өр-яңа диагностика аппаратурасы белән тәэмин итә. Кафедрада ул тәрбияләгән талантлы табиблар эшли. Клиникада дәвалау эше бик югары дәрәҗәдә оештырылып, авыруларны яңача дәвалау ысуллары эшләнә. Профессор атнага өч тапкыр авырулар янына кереп, аларның хәлен белешә торган була. Җитәкче һәм уникаль клиницист буларак, Терегулов хезмәткәрләр, ординаторлар, аспирантлар һәм студентлар белән үзенең таланты һәм тәҗрибәсе белән уртаклаша, авырулар һәм халык алдында чиксез ихтирам казана.

Сугыштан соңгы елларда Ә.Г.Терегулов сулыш физиологиясе һәм патологиясе темасыннан ашкайнату системасы органнарын өйрәнүгә күчә. Ул югары дәрәҗәдәге конференцияләрдә һәм съездларда ясалган докладларында бу яңа проблеманы яктырта, коллегалары белән хезмәтләрен тәкъдим итә. Мәсәлән, 1947 елда ул терапевтларның XIII корылтаенда бик әһәмиятле доклад-программа белән чыгыш ясый, анда язва авыруын диагнозлау һәм дәвалау мәсьәләләрен күтәрә. Ә.Г.Терегулов җитәкчелегендә биш докторлык һәм унбер кандидатлык диссертациясе яклана, темалары клиника эшенә, яңалык буларак, уңай йогынты ясаган 200дән артык фәнни язмасы дөнья күрә.

Галим актив җәмәгать эшчәнлеге алып бара. Ул ТАССР Югары Советының II, III, IV, V чакырылышларында депутат, Казан медицина фәнни оешмалары Советы җитәкчесе, ТАССР

терапевтларының фәнни оешмасы рәисе була. Бөтенсоюз терапевтлар оешмасы идарәсенә әгъза итеп сайлана. Тырыш хезмәте өчен, ул абруйлы медальләргә лаек була. 1950 елда икенче кабат Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, 1952 елда Ленин ордены белән бүләкләнә.

Ә.Г.Терегулов җитәкләгән кафедра, заманча фән һәм техника казанышларын киңрәк куллану максатында, махсус конструкторлык-технология бюросы ачу инициативасы белән чыга. 1955 елда Казанда «Медфизприбор» дип аталган завод ачылып, анда, пациентның сулышы һәм башка әгъзалары эшчәнлеген өйрәнү һәм дәвалау өчен, яңа приборлар, аппаратлар, җайланмалар эшләнә башлый. Кафедра заводның клиника-эксперимент базасы булып китә.

Россиядә күптән чыгып килеп, сугыш елларында тукталып торган «Казан медицина журналы»ның 1957 елда яңадан басыла башлавы да Ә.Г.Терегуловның зур тырышлыгына бәйле. Ул Идел буе халыкларына аеруча мөһим булган, хәзер ВАК исемлегенә кергән бу журналның мөхәррире (1959 елга кадәр), аннан соң редколлегия әгъзасы булып тора.

Ә.Терегулов Татарстан Республикасының кешегә шифалы табигый байлыклары белән дә даими кызыксына, тикшеренүләр ясый. Хәзер ашказанын дәвалауда киң кулланыла торган Ижау суын халыкка танытуда аның җитди өлеше бар. Галимнең Казан терапия мәктәбенең нигез ташларын салган һәм аның үсешен тәэмин иткән профессорлар Н.А.Виноградов, А.Н.Казем-Бек, С.С.Зимницкий, Н.К.Горяев, М.Н.Чебоксаров кебек шәхесләргә багышланган язмалары игътибарга лаек.

1963 елда Ә.Г.Терегулов пенсиягә китсә дә, кафедра эшеннән читләшми, аның фәнни җитәкчесе булып кала. Әүвәлге фәнни хезмәтләре ашказаны, аның баш мие белән бәйләнеше, бөер эшчәнлеге, йөрәк проблемалары һәм шулардагы табигый булмаган тайпылышларны тикшерүгә багышланса, соңгы еллардагы гыйльми эзләнүләрен ул, кешелеккә бәла булып, киң таралган атеросклероз авыруын өйрәнүгә һәм аңа каршы көрәшкә юнәлтә.

Галим 1966 елда 81 яшендә бакыйлыкка күчә.

Әбүбәкер Гәрәй улы Терегулов медицина өлкәсендә татар милләтеннән беренче профессор буларак танылып, шушы юнәлешнең үсешенә зур өлеш керткән педагог, гаҗәеп эшлекле шәхес, талантлы табиб-терапевт, берничә буын табиблар остазы булып, тарихка кереп калды. Казанның беренче хастаханәсенә, Горки-3 микрорайонындагы бер урамга профессор Ә.Г.Терегулов исеме бирелде. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе медицина өлкәсендә башкарылган күренекле хезмәтләре өчен Ә.Г.Терегулов исемендәге премия булдырды. Табиб Г.Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романында Әбүзәрнең прототибы итеп алынып, аның якты образы матур әдәбиятта да чагылыш тапты.

**Әдәбият**


1. *Терегулов А.Г.* Болезни органов кровообращения – острые миокардиты; острый ревматизм / Справочник начинающего советского врача. Казань: Татиздат, 1933. С. 65-87.
2. *Терегулов А.Г.* Клинико-лабораторное исследование и курация больного с заболеванием внутренних органов. Казань: Таткнигоиздат, 1959. 120 с.
3. *Абдрахманова А.Ш., Маянская К.А.* Профессор Абубекир Гиреевич Терегулов // Казанский медицинский журнал. 1985. Т. 86, №2. С. 155-156.
4. *Шәмсетдинов Н.Ш.* Әбүбәкер Терегулов һәм аның иҗаты // «Фән һәм тел» журналы, 2000, №1. 33-35 б.